КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1173

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы; 2016 ел, 7 июль, 462 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2017 ел, 7 август, 562 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 13 июнь, 490 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 749 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибендә:

6 нчы пунктның таблицасындагы 8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | Идарә итүче компанияләр, | Түбәндәгеләрне исәпләү һәм алар турында мәгълүматлар бирү:<br>фактта күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү, антенна хезмәте күрсәтү өчен | электрон | хисап аеннан соң килүче айның 3 сенә кадәр | РМЯҮ бүлекләре». |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | ТКХК, ХҮ | исәпләүләр, шәхсиләштерелгән социаль счетлар яктылыгында коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән файдалану нормативлары;<br>торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар булмау;<br>ике ай эчендә торак урын һәм (яки) коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен агымдагы түләүләрне түләмәү;<br>гражданнар тарафыннан бурычларны түләү буенча килешүләр төзү һәм (яки) аларны үтәү;<br>коммуналь хезмәтләрне өзү факты;<br>коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты;<br>торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны | | | |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

1 бүлекнең 1.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Нигезләмә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр (алга таба – ТКХ) өчен түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чараларына хокукы булган гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр (алга таба – ташлама-субсидияләр) бирү тәртибен һәм шартларын җайга сала.»;

2 бүлекнең 2.4 нче пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташлама-субсидияләр бирүне туктату (яңадан бирә башлау) турындагы карар ташлама-субсидияләр бирүне туктатуга (яңадан бирә башлауга) китерә торган вакыйгалар турында ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә мәгълүмат алган көннән 10 эш көне эчендә кабул ителә һәм алучыга карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә гаризада гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хат итеп) хәбәр ителә.»;

3 бүлекнең 3.1 нче пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Vi – торак һәм коммуналь хезмәтләрне куллану күләме. Торак һәм коммуналь хезмәтләрнең һәрберсен куллану күләме гаиләнең һәр әгъзасына тигез күләмдә туры килә торган гомуми гаилә чыгымыннан чыгып билгеләнә. Гаилә әгъзалары санын билгеләгәндә теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге юридик затлар яки күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләр, торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары тарафыннан йә, идарә итүче яки ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар (алга таба – идарә итүче компанияләр) белән килештереп, торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән күздә тотылган тәртиптә хисаплауны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан бирелгән яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны турындагы мәгълүматлар исәпкә алына. Идарә итүче компанияләрнең мәгълүматлары булмаганда, гаилә әгъзаларының санын билгеләгәндә индивидуаль торак фондында яки күпфатирлы торак фондында яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән шартнамәләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмалар тарафыннан бирелгән яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарның иң күп саны турындагы мәгълүматлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «То-рак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән күздә тотылган тәртиптә кулланыла. Электр һәм җылылык энергиясе, су һәм газ челтәрендәге газ өчен исәпкә алу приборлары күрсәткечләре буенча түләүче гражданнарга ташлама-субсидияләр күләмен билгеләгәндә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән файдалану күләменең факттагы мәгънәсе кулланыла. Факттагы куллану күләме билгеләнгән куллану нормативларыннан артып киткән очракта, федераль законнар белән башкасы күздә тотылмаган булса, норматив мәгънә кулланыла. Торак мәйданның социаль нормасының билгеләнгән мәгънәләре торак мәйданның факттагы зурлыгыннан артканда, исәп-хисапларда торак мәйданның факттагы зурлыгы кулланыла;»;

5 бүлекнең 5.1 нче пунктында «федераль компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «федераль бюджеттан» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин